Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Тауасты Байлар авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

№3 18 сентябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 - ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә: ТР, Минзәлә районы Тауасты Байлар авылы, Үзәк Байлар авылы, 14 а, Дәвек авылы, Совет урамы, 35, Мияш авылы, Лесная урамы, 19 һәм Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга район http://menzelinsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы И.Р. Мәүзиев